ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛЫН-БАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2026 ел, 10 апрель №17

Болын-Балыкчы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Терлекләр белән хуҗаларсыз эш итү чараларын оештыру максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Апас районы Прокуроры протесты нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикассы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советының 2017 елның 9 мартындагы 46 номерлы карары белән расланган Болын-Балыкчы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 18.18 пункт өстәргә:

«18.18. Хайваннарны торак массивлары, җәмәгать урыннары һәм социаль объектлар территориясендә хуҗаларсыз тукландыру тыела, моңа җирле үзидарәнең махсус оештырылган органы тарафыннан хайваннарны хуҗаларсыз ашату урыннары керми.»;

2)4.3 пунктындагы өченче абзацны, 36-39.6 пунктларын, 55.1, 65, 110-116.6,177 пунктын төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районының
Болын-Балыкчы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Гайнетдинов